КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 июль г.Казань № 790

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йорт өчен авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында» 2017 ел, 9 ноябрь, 857 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 август, 702 нче, 2019 ел, 25 декабрь, 1198 нче, 2021 ел, 13 август, 707 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йорт өчен авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Т.Т.Әһлиуллинны, М.М.Әхмәтовны, Д.А.Бакированы, Е.А.Врачевны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне consultantplus://offline/ref=6F611356638D625FEA8427BA1F91C740D24849B06B44EEC8561E3BB98AD89150B3412E5EF6B97261AF24B62DC69CB7B7EE7A22FAF068E6A6DD00548819tBHкертергә:

| | |
|---|---|
| Камаев Радик Рафаил улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлегенең баш киңәшчесен |

| | |
|---|---|
| Меркурьева Юлия Алексеевнаны | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак шартларын яхшырту буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү бүлеге башлыгын |
| Хуҗиева Алсу Рафаэл кызын | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак шартларын яхшырту буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү бүлеге баш киңәшчесен. |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими яшәү урынынннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 12 гыйнвар, 3 нче карарының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 май, 624 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 пунктында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин